| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| 05.09.2023 | | 1029-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 19 июнендәге 502-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актын Татарстан Республикасы законнары белән тәңгәлләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 19 июнендәге 502-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты

байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 12 сентябрендәге 797-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Каты файдалы казылма геологиясе бүлегенә (С.А. Шутникова) югарыда аталган Регламент нигезендә эшләр башкарылуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары А.А.Тугушевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
19.06.2022 ел, № 502-п
боерыгы белән расланды
(05.09.2023 ел, № 1029-п
боерык редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1.1.Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте, Регламент) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып җир асты байлыкларыннан файдаланучылар – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затлар, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгән

Россия Федерациясе гражданнары булган шәхси эшкуарлар (алга таба –мөрәҗәгать итүче) тора.

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле булып тиешле вәкаләтләрнең үзенә бирелүен раслый торган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар нигезендә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын (алга таба – проект документлары) килештерү.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык)

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

2.3.1. Проект документациясен килештерү турында карар, проект документациясен килештерү өлешендә:

а) файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектлары:

киң таралган файдалы казылмаларга карата – ятмаларны сынау-сәнәгый эшкәртү проекты, ятмаларны эшкәртүнең техник проекты, гомумтаралган файдалы казылмаларны беренчел эшкәртүнең технологик схемасы һәм аларга үзгәрешләр;

эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү яки техник су белән

тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 кубик метрдан артып китмәгән җир асты суларына карата, – ятманы (кишәрлекне) сынау-сәнәгый эшкәртү проекты, ятманы (кишәрлекне) эшкәртү проекты һәм аларга үзгәрешләр;

файдалы казылмалар чыгару һәм файдалы компонентлар максатларында файдаланылырга тиешле җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга тапшырылган җир асты байлыкларыннан, шул исәптән ярып табылган һәм аларны сыйдырышлы тау токымнары калдыкларына карата (җир асты байлыкларыннан файдалану калдыклары, шул исәптән ярылган һәм сыйдырышлы тау токымнары калдыклары, файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бирелә торган геологик мәгълүмат нигезендә мөстәкыйль сәнәгать әһәмиятенә ия булган очракта), – ятманың сынау-сәнәгый эшкәртү проекты, ятманы эшкәртүнең техник проекты, минераль чималны беренчел эшкәртүнең технологик схемасы һәм аларга үзгәрешләр;

б) җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектлары – җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектлары, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектлары;

в) тау эшкәртмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләү буенча техник проектлар:

киң таралган файдалы казылмаларга карата – тау эшкәртмәләрен, бораулау скважиналарын, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны бетерү яки консервацияләүнең техник проекты һәм аңа үзгәрешләр;

эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб. метрдан артмаган җир асты суларына карата – җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган тау эшкәртмәләрен, бораулау скважиналарын, башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проекты, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, һәм аңа үзгәрешләр;

җир асты корылмаларына карата – файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын бетерү яки консервацияләүнең техник проекты һәм аңа үзгәрешләр (алга таба – техник проектлар).

2.3.2. Проект документациясен килештерүдән баш тарту турында карар.

2.3.3. Мәгълүмат системасында мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу фактын теркәү зарурлыгы юк.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә яки аның законлы вәкиленә бирелә (җибәрелә):

гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына һәм (яки) Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучылар һәм геология оешмаларының «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты»на (мондый функция булдырылганнан соң), яисә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) дәүләт мәгълүмат системасында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон үрнәге шәхси кабинетка автомат рәвештә җибәрелә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы яисә аның вәкаләтле вәкиле проект документациясен килештерү яисә проект документациясен килештерүдән дәлилләнгән баш тарту турында тиешле гариза нигезендә кәгазь чыганакта өстәмә карар алырга хокуклы.

2.3.5. Проект документациясен килештерү яки проект документациясен килештерүдән баш тарту турында карар, шулай ук мондый карардагы мәгълүматлар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт һәм муниципаль функцияләрне электрон формада башкару өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктура аша кызыксынучы дәүләт хакимияте органнарына электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталы аша (әлеге функцияне гамәлгә ашырганнан соң) электрон документлар рәвешендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм теркәлә торган документлар теркәлгән көннән алып 20 эш көне эчендә күрсәтелә, шул исәптән:

Проект документларын карау вакыты – 15 эш көне;

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты – проект документациясен килештерү яки проект документациясен килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне.

Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша электрон документлар рәвешендә тапшырылган очракта, дәүләт

хезмәте гариза һәм кушымта итеп тапшырылган документлар теркәлгәннән соң 20 эш көне эчендә күрсәтелә, шул исәптән:

Проект документларын карау вакыты – 15 эш көне;

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты – проект документациясен килештерү яки проект документациясен килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне.

Файдалы казылма ятмаларын уникаль һәм зур файдалы казылма ятмаларына карата эшкәртүнең техник проектларын карау срогы арттырылырга мөмкин, әмма 25 эш көненнән дә күбрәк түгел, бу хакта җир асты байлыкларыннан файдаланучыга проект документларын карау срогын озайту турында карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә хәбәр җибәрелә.

2.4.2. Әгәр проект документациясен караганда Регламентның 2.8.2 пунктында каралган проект документациясен килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булуы ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтү аны туктатуга китергән нигезләрне бетергәнче, әмма 30 көннән дә артык булмаган вакытка туктатылырга мөмкин, бу хакта җир асты байлыкларыннан файдаланучыга гаризаны теркәгән көннән алып 10 эш көненнән дә артмаган вакытта хәбәр җибәрелә.

2.4.3. Әгәр проект документациясен караганда җир асты байлыкларыннан файдалану шартларына һәм (яки) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә билгеләнгән җир асты байлыкларыннан файдалану срогына туры килмәве ачыкланса, регламентның 2.8.2 пунктында каралган проект документациясен килештерүдән баш тарту өчен башка нигезләр булмаса, дәүләт хезмәте күрсәтү аны туктатып торуга китергән нигезләрне бетергәнче, әмма 10 көннән артык булмаган вакытка туктатылырга мөмкин, бу хакта җир асты байлыкларыннан файдаланучыга проект документациясен карау вакыты тәмамланганчы 5 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр җибәрелә.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында урнаштырылган.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче гариза (Регламентка 1 нче кушымта) тапшыра, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) җир асты байлыкларыннан файдаланучының исеме һәм оешу-хокук формасы, дәүләт теркәве турындагы язуның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, урнашу урыны адресы, телефоны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучының электрон почта адресы – юридик зат өчен;

б) шәхесне раслаучы документның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган

очракта), яшәү урыны, телефоны һәм электрон почта адресы) – шәхси эшкуар өчен;

в) килештерүгә тапшырыла торган проект документларының атамасы;

г) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга барлык үзгәрешләр реквизитлары булган лицензия реквизитлары;

д) файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларының дәүләт экспертизасы, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реквизитлары (булган очракта);

е) комиссиянең яисә вәкаләтле органның алдагы карары реквизитлары (әгәр проект документларын карау кабат үткәрелсә.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

а) җир асты байлыкларыннан файдаланучының вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган проект документациясе;

б) затның җир асты байлыкларыннан файдаланучы исеменнән гамәлләр башкару вәкаләтләрен раслаучы документ (документлар), гаризага шәхси эшкуар (әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы шәхси эшкуар булса) яки юридик зат исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эш итү хокукына ия булган зат буларак юридик затларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән зат (әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы юридик зат булса) кул куйган очраклардан тыш. Әлеге документ машина аркылы укыла торган рәвештә рәсмиләштерелергә мөмкин. Әгәр ышаныч кәгазе шәхси эшкуар булмаган яки юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик зат исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эш итәргә хокуклы зат буларак күрсәтелмәгән зат тарафыннан имзаланган икән, мондый затның ышаныч кәгазен бирү вәкаләтләрен раслаучы документларны тапшыру таләп ителә;

в) ярылган һәм сыйдырышлы тау токымнарын тапшыруны күздә тоткан шартнамәнең яисә күчермәсе, шул исәптән Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 157 статьясы нигезендә кичектерү шарты белән төзелгән (ярылган һәм сыйдырышлы тау токымнарын куллану буенча «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 23.5 статьясындагы беренче өлешенең 6 һәм 7 пунктларында каралган максатлар өчен техник һәм технологик карарлар әзерләнгән очракта) (булган очракта).

2.6.2. Гариза һәм теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар формасында түбәндәге ысулларның берсе белән тәкъдим ителергә мөмкин:

1) Регламентның 2.6.4 пункты таләпләренә туры китереп имзаланган, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталыннан файдалану юлы белән (әлеге функция булдырылганнан соң).

Проект документларын кәгазьдә тапшыру таләп ителми.

Проект документациясе бүлекләре электрон рәвештә бирелә һәм Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат сервислары ярдәмендә формалаштырыла.

Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, шулай ук әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында бар.

2.6.3. Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне аның шәхси кабинетында гаризаның кабул ителүен һәм гаризаны тапшыру датасы буенча раслама ала, анда гаризаны теркәү номеры һәм кабул итү датасы күрсәтелгән була.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталыннан (мондый функция булдырылганнан соң) файдалану юлы белән тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон формалы документларны тапшыра.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүчеләр (шәхси эшкуарлар) гаризага гади электрон имза белән кул куя.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешләрен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – бердәм система) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

Дәүләт серенә караган белешмәләр булган материаллар дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп тапшырыла.

2.6.5. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

- комиссиянең яисә вәкаләтле органның алдагы карары күчермәсе (әгәр проект документларын карау кабат үткәрелсә). Гариза Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына җибәрелә;

- файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларының дәүләт экспертизасы, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең күчермәсе. Гариза «Идел буе федераль округы буенча Геологик мәгълүмат территориаль фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалына җибәрелә);

- җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия күчермәсе. Гариза Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына җибәрелә.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм Регламентның 2.6.3 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

- электрон формадагы гариза һәм документлар 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып, электрон имза белән имзаланган очракта;

- гаризада һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистарту, өстәп язу урыннары һәм төзәтмәләр булуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән формага туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса,

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- Регламентның 2.8.2 пунктында каралган проект документларын килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булуы.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) проект документациясенең җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә билгеләнгән җир асты байлыкларыннан файдалану шартларына һәм (яки) Россия Федерациясенең җир асты байлыклары турында закон таләпләренә туры килмәве;

б) проект документларының Регламентның 2.6.1 пункты таләпләренә һәм (яки) җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм саклау таләпләренә туры килмәве;

в) проект документларында, файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән белешмәләрнең, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматның туры килмәве;

г) проект документларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 ноябрендәге 2127 номерлы карары белән расланган Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, тау эшкәртмәләрен, бораулау скважиналарын һәм файдалы казылмаларның төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын әзерләү, килештерү һәм раслау кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 9 пунктында каралган файдалы казылмаларның төрләре буенча файдалы казылмаларның ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән техник проектларның составына һәм эчтәлегенә, шулай ук җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектлары структурасына һәм аларны рәсмиләштерүгә карата, тау эшкәртмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектлары таләпләргә туры килмәве.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

**2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары**

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

**2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты**

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

**2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.**

2.11.1. Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталыннан (мондый функция булдырылганнан соң) файдаланып җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гаризаны теркәү көнендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы «шәхси кабинеты»на яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты»на һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшыру датасы күрсәтелгән була.

2.11.2. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталыннан (мондый функция булдырылганнан соң) электрон формада ял (бәйрәм) көнендә, эш сәгатьләре булмаган вакытта алынган гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган чираттагы эш көнендә теркәлә.

**2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр**

2.12.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән

тәэмин ителгән Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча яраклаштырып булмаса, аларны реконструкцияләгәнчегә һәм капиталь ремонтлаганчыга кадәр, Министрлык Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренең берсе белән килештереп, мумөикн булган очракта, инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына керүен тәэмин итү өчен чаралар күрергә яисә кирәкле хезмәтләрне инвалидның яшәү урыны буенча яисә дистанцион режимда күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш.

2.12.4. Автотранспорт чаралары парковкаларында инвалидларның махсус автотранспорт чараларын кую өчен кимендә бер урын бирелә.

Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» тану билгесе билгеләнергә һәм әлеге транспорт чаралары турындагы мәгълүмат инвалидларның федераль реестрына кертелергә тиеш.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;
- белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның зарури санда булуы;
- дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында тулы мәгълүмат булуы.
- электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;
- дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү;
- дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы, инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү;

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- документларны кабул итү һәм карау срокларыныэ үтәлүе;
- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогының үтәлүе;
- дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыктан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеттан алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрне карау Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы «Шәхси кабинетта» мөрәҗәгать итүчене алдан авторизацияләмичә башкарыла.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Шәхси кабинет»та авторизация узганнан соң мөрәҗәгать итүченең мөмкинлекләре:

- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны бирергә;
- кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон үрнәкләрен (график файлларны) беркетергә;
- дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;
- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат алырга.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә гади электрон имза

ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү процедурасын узарга кирәк. ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

**2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында**

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) документлар җыелмасын билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча тикшерү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә юллау;

6) проект документларына кертелә торган үзгәрешләрне әзерләү, килештерү һәм раслау;

7) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче Каты файдалы казылма геологиясе бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында консультация алырга хокуклы.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Әгәр гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга тели икән, Министрлык мөрәҗәгать итүчене язмача консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать

иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталы (мондый функция булдырылганнан соң) аша гади электрон имза яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасындагы гаризаны Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизация уза;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.3.1.1. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан алынуы административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша документлар карауга тапшырылганнан соң административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Бүлек белгече:

гаризага эш номенклатурасы буенча номер һәм «Документларны тикшерү» статусын бирә, бу Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта чагылдырыла;

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталына керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентка 2 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелсә) Электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гариза алынган көннән башлап бер эш көненнән соңга калмыйча җибәрелә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы пунктлары булырга тиеш.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза алынган көннән соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.3.1.2. Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар үтәлеше, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карап тикшерүгә кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче гаризаны Министрлыкка биргән очракта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси инициатива буенча тапшырылмаган булсалар, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган тиешле дәүләт органнарыннан Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрә:

- комиссиянең яисә вәкаләтле органның алдагы карары күчермәсен тапшыру турында (әгәр проект документларын карау кабат үткәрелсә). Гариза Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына җибәрелә;

- файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларының дәүләт экспертизасы, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең күчермәсен бирү турында. Гариза «Идел буе федераль округы буенча Геологик мәгълүмат территориаль фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалына җибәрелә);

- җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия күчермәсен бирү турында. Гариза Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына җибәрелә.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

3.4.2. Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне - дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау.

3.5.1. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган электрон формадагы документларны исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедурасын үти башлау өчен Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән барлык документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка тапшырылуы нигез булып тора.

3.5.1.1. Бүлек белгече 1 эш көне эчендә Министрлыкның боерыгы белән раслана торган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм куллануд агы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын карау комиссиясендә (алга таба – Комиссия) карауга тапшыру өчен документлар җыелмасын формалаштыра һәм аларны өйрәнү өчен аның әгъзаларына җибәрә.

3.5.1.2. Проект документларының «Җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау» бүлеге, табигатьне саклау законнары таләпләрен үтәү өлешендә карау өчен, Комиссия составына керми торган Министрлыкның Экологик куркынычсызлыкны һәм экология мониторингын тәэмин итү идарәсе һәм Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе белгечләренә тапшырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган һәм Комиссия әгъзаларына карап тикшерүгә җибәрелгән документлар пакеты.

3.6. Регламентның 2.6 пунктында каралган таләпләргә туры килми торган яисә Регламентның 2.6 пунктын бозып бирелгән материаллар җир асты байлыкларыннан файдаланучыга яисә аның вәкаләтле вәкиленә, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылган көннән алып 5 эш көне эчендә материаллар бирелгән ысул белән кире кайтарыла.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору.

3.7.1. Проект документларын караганда Комиссия проект документациясен килештерүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр барлыгын ачыклаган очракта, гаризаны теркәгән көннән башлап 10 эш көненнән артмаган срокта җир асты байлыкларыннан файдаланучыга, җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнарының конкрет нормаларын, җир асты байлыкларыннан файдалануның конкрет шартларын, файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең конкрет нигезләмәләрен, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматны, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү буенча техник проектлар әзерләү кагыйдәләренең конкрет таләпләрен, шулай ук җир асты корылмаларын төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектлары структурасына һәм рәсмиләштерүгә, тау эшкәртмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны юкка чыгару һәм консервацияләүнең техник проектларына карата Кагыйдәләрнең 9 пунктында каралган таләпләрне күрсәтеп, мондый проект документациясен эшләп бетерү кирәклеге турында хәбәр җибәрә.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәр җир асты байлыкларыннан файдаланучыга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталы (мондый функция булдырылганнан соң) яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә (әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән булса).

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы яки аның вәкаләтле вәкиле әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән хәбәрдә күрсәтелгән искәрмәләр буенча эшләп бетерелгән проект документларын мондый хәбәр Регламентның 2.6 пунктында билгеләнгән тәртиптә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җибәрелгән көннән башлап 30 эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәрне җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җибәргән көннән башлап проект документларын карау срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы яки аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан эшләп бетерелгән проект документларын тапшырганчыга кадәр, әлеге пунктның өченче абзацында каралган эшләп бетерелгән проект документларын тапшыру срогы бетәчәк датага кадәр туктатып торыла.

Эшләп җиткерелгән проект документациясе барлык кертелгән үзгәрешләрне тасвирлап, аңлатма язуы белән озатыла.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәрдә каралган искәрмәләр буенча эшләнеп беткән проект документациясен караганда, бу проект документациясендә җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан җитешсезлекләрне бетергәндә үзгәртелмәгән мондый проект документациясенең бүлекләрен (өлешләрен) карау гамәлгә ашырылмый.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәр җибәрелгән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, җир асты байлыкларыннан файдаланучы яисә аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан эшләнеп беткән, аңа карата Регламентның 2.8.2 пунктында каралган проект документациясен килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган проект документациясе тапшырылган очракта, проект документациясен карау срогы яңартыла һәм проект документациясен килештерү турында карар кабул ителә.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәр җибәрелгән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, җир асты байлыкларыннан файдаланучы яисә аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан эшләнеп беткән, аңа карата Регламентның 2.8.2 пунктында каралган проект документациясен килештерүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган проект документациясе тапшырылган очракта, яисә эшләнеп беткән проект документациясе тәкъдим ителмәсә, проект документациясен карау срогы яңартыла һәм проект документациясен килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

3.7.2. Проект документларын караганда, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә билгеләнгән җир асты байлыкларыннан файдалану шартларына һәм (яисә) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогына туры килмәве ачыкланган очракта, Регламентның 2.8.2 пунктында каралган проект документациясен килештерүдән баш тарту өчен башка нигезләр булмаса, Комиссия җир асты байлыкларыннан файдаланучыга Регламентның 2.4.1 пункты нигезендә проект документациясен карау срогы тәмамланганчы 5 эш көненнән дә соңга калмыйча бу хакта язмача хәбәр итә.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәр җир асты байлыкларыннан файдаланучыга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталы (әлеге функция булдырылганнан соң) яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә (әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән булса).

Комиссия тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында каралган язмача белдерү җибәрелгән очракта, проект документларын карау срогы күрсәтелгән хәбәр җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җибәрелгән көннән алып 10 эш көненә туктатып торыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы яки аның вәкиле тарафыннан, әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәрне алганнан соң, «Җир асты байлыклары

турында» Россия Федерациясе Законының $12^1$ статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр кертүгә гариза тапшырылган очракта, проект документациясен карауны туктатып тору срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы яисә аның вәкаләтле вәкиле гаризасы буенча әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәрне җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җибәргән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көнгә кадәр яисә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр кертү турында карарлар кабул итүче комиссия җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул иткән көнгә кадәр озайтыла.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәр җир асты байлыкларыннан файдаланучының яки аның вәкаләтле вәкиленең җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр кертү гаризасы буенча белдерүдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында аны биргән көннән башлап 5 эш көненнән артмаган срокта җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр кертү турында карарлар кабул итүне гамәлгә ашыручы комиссиягә дә җибәрелә. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының яки аның вәкаләтле вәкиленең җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр кертү гаризасы буенча лицензиягә үзгәрешләр кертү турында (җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар турында мәгълүмат әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 5 эш көненнән артмаган срокта комиссиягә әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәрдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча җибәрелә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы яисә аның вәкаләтле вәкиле проект документациясен карауны туктатып тору турында гариза тапшырмаган очракта, проект документларын карау срогын яңарту әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәр җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җибәрелгәннән соң 10 эш көне узгач гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы яисә аның вәкаләтле вәкиле проект документациясен карауны туктатып тору турында гариза тапшырылган очракта, «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 28 статьясында каралган файдалану өчен тапшырылган җир асты байлыклары участокларының һәм җир асты байлыкларыннан файдалану лицензияләренең дәүләт реестрында җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүмат урнаштырылган көннән яисә комиссия тарафыннан әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында мәгълүмат алынган көннән алып 3 эш көненнән соңга калмаган чорда гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Проект документларын карау нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан проект документларын килештерү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында карар кабул ителә һәм Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, Комиссия утырышына рәислек итүче зат тарафыннан раслана һәм проект документларын килештерү (килештерүдән баш

тарту) турында боерык проектын әзерләү өчен Бүлеккә җибәрелә.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә юллау.

3.8.1. Комиссия карарын исәпкә алып, Бүлек белгече проект документларын килештерү (килештерүдән баш тарту) турында боерык проектын рәсмиләштерә һәм аны имзалау өчен министрга яки аны алмаштыручы затка җибәрә.

Министр яисә аны алмаштыручы зат, проект документларын килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карар проектын имзалау юлы белән, проект документларын килештерү (килештерүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

Боерык белән рәсмиләштерелгән карар шул ук көнне Министрлыкның эш башкару бүлегендә дә теркәлергә тиеш.

3.8.2. Проект документларын килештерү (килештерүдән баш тарту) турында карар кабул итү критериясе булып Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән проект документларын килештерүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуы яисә булмавы тора.

Административ процедураның соңгы нәтиҗәсе булып, Министрлык боерыгы рәвешендә проект документларын килештерү (килештерүдән баш тарту) турында карар тора, ул Бүлеккә тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.7 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрның яисә вәкаләтле министр урынбасарының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган материалларны килештерү (килештерүдән баш тарту) турында Министрлык карары.

3.8.3. Проект документациясен килештерү турында (проект документациясен килештерүдән баш тарту турында) карар җир асты байлыкларыннан файдаланучыга карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне дәвамында гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына электрон рәвештә җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) проект документларын килештерү (килештерүдән баш тарту) турында карар җибәрү (бирү).

3.8.4. Проект документациясен килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, җир асты байлыкларыннан файдаланучы яки аның вәкаләтле вәкиле проект документациясен, аны эшләп бетерү буенча киңәшләрне исәпкә алып, килештерүгә кабат җибәрергә хокуклы.

3.8.5. Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрне әзерләү, килештерү һәм раслау проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.9. Техник хатаны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ;

техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны (язу, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның һәм геологик оешмаларның «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты» порталы (мондый функция булдырылганнан соң), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшыра.

3.9.2. Бүлек белгече техник хатаны (язу, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән бергә терки. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең (вәкаләтле вәкилнең) электрон почтасы аша Бүлеккә техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыклангганнан соң яки мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан җибәрелгән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) турында гариза алынганнан соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Административ регламент процедураларында билгеләнгән административ гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.5. Административ регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге административ регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы

норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына
кемнән ______________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Гариза

проект документларын килештерү турында

______________________________________________________________,

(юридик зат өчен – мөрәҗәгать итүченең исеме (тулы һәм кыскартылган) һәм оешу-хокук рәвеше, дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәнгәллек номеры, урнашу урыны адресы, телефоны һәм электрон почта адресы)

______________________________________________________________________________
(шәхси эшкуар өчен – шәхесне раслаучы документның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, телефоны һәм электрон почта адресы)

Килештерүгә җибәрәбез
______________________________________________________________________________
(проект документациясенең исеме)
______________________________________________________________________________
(гомумтаралган файдалы казылма ятмаларынын/җир асты суларының атамасы)
______________________________________________________________________________
(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензиянең барлык үзгәрешләре булган реквизитлары)

______________________________________________________________________________

(файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларының дәүләт экспертизасы, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реквизитлары (булган очракта))

______________________________________________________________________________

(алдагы карарның реквизитлары (әгәр проект документациясен карау кабат уздырылса))

Теркәлә торган документлар исемлеге:

1.________________________________________________________________________

2.________________________________________________________________________

3.________________________________________________________________________

4.________________________________________________________________________

5.________________________________________________________________________

(теркәлә торган документларның барлык исемлеген күрсәтергә)

Җитәкче___________________________________/________________________/

(имза) (тулы имза)

Башкаручы (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) тулысынча).
Элемтә телефоны, e-mail

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар ___________________________________

Түбәндәгенең мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә ___________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

гариза №_____ _____ елның ____._____.________, ___________________________________

___________________________________________________________________________

нигезе: ___________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________.

Җитәкче__________________________________/_______________________/

(имза) (тулы имза)

Башкаручы

(фамилия, исем, ата исеме )____________________________

(башкаручының элемтә белешмәләре)

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

(киңәш ителә торган рәвеше)

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры

________________________________

кемнән_____________________________

(юридик зат өчен – мөрәҗәгать итүченең исеме (тулы һәм кыскартылган) һәм оешу-хокук рәвеше, дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, урнашу урыны адресы, телефоны һәм электрон почта адресы)

________________________________________________

(шәхси эшкуар өчен – шәхесне раслаучы документның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, телефоны һәм электрон почта адресы)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
____________________________________________________________

(дәүләт хезмәте атамасы)

Язылган:______________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат: ____________________________________________________

______________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.____________________________________________________________________

2.____________________________________________________________________

3.____________________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар хакында:

- email адреска электрон документ җибәрү юлы белән: ________________________

_______________________________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

_____________________________________________________________________.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

_____________ ________________ _________________________________

(дата) (имза) (фамилия, исем һәм ата исеме (булган очракта))

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-60 | Almaz.Tugushev@tatar.ru |
| Минераль-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе в.б. | 267-68-35 | Samat.Vahitov@tatar.ru |
| Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе | 267-68-97 | Svetlana.Shutnikova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov @tatar.ru |